Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советының егерме беренче утырышы

Кибәч авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

14 декабрь, 2022 ел № 57

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлегендә гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 21 августындагы 21номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлегендә гавами тыңлауларны, иҗтимагый фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (2017 елның 12 декабрендәге 85, 2018 елның 25 маендагы 98, 2019 елның 20 сентябрендәге 133 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 өлештә:

а) 4.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулары билгеләү турындагы хәбәр, аларны үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, «Вперёд» («Алга») район газетасының вакытлы матбугат басмасында гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулары уздырылган көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

б) 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турындагы карар, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, иҗтимагый фикер алышулары гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасында» урнаштырылырга тиеш (алга таба - Бердәм портал).

Бердәм порталда халыкның халыкка хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында мәгълүмат урнаштыру, авыл җирлеге башкарма

комитетының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан, шәхси кабинеттан файдаланып, Бердәм порталның әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокта кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә гамәлгә ашырыла.».

5 өлешнең 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәрен, муниципаль норматив хокукый акт проектына җәмәгатьчелек фикер алышуларын шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә Бердәм портал юлы белән җибәрергә хокуклы.

Фикер алышуга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр, электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган «Мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, Бердәм порталдан файдаланып, җирлектә яшәүчеләр тарафыннан кертелә.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар уздырылган көнгә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертелгәндә, җирлек халкы шулай ук үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләр җибәрә.

Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыручының шәхси кабинетына җибәрелә.».

1.3. 7 өлешнең 7.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

Җирле үзидарә органнары өчен йомгаклау документлары рекомендация характерында.

1.4. 12 өлешнең 12.1 пунктында «кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов